МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

«4» марта 2009 г. | № 499/09

Казань

# Белем бирүнең вакытлы дәүләт стандартларын раслау турында

Россия Федерациясе “Мәгариф турында”гы Законының 7 нче статьясында каралган белем бирү федераль дәүләт стандартларының 11 ел эчендә гамәлгә керүен һәм Россия Федерациясе күләмендә туган тел һәм әдәбият, региональ фәннәр буенча программалар, укыту-методик комплектлар булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы “Мәгариф турында”гы Законының 7 нче статьясына нигезләнеп һәм белем бирүнең эчтәлеген яңарту, аның сыйфатын күтәрү максатыннан, **боерам**:

1. Татар теле, татар әдәбияты, татар халкы һәм Татарстан тарихыннан гомуми белем бирүнең вакытлы дәүләт стандартларын расларга (1, 2, 3 нче кушымталар).
2. Басма кулланмалар һәм укыту-методик әдәбият бүлегенә (С.А.Корнилов) түбәндәге фәннәрдән үрнәк укыту программалары һәм укыту-методик комплектлар төзү буенча ачык конкурс игълан итүне оештырырга:

а) гомуми башлангыч белем бирү баскычы өчен (1-4 сыйныфлар) татар теле һәм әдәби укудан (*укыту татар телендә алып барыла торган мәктәпләр һәм сыйныфлар; укыту рус телендә алып барыла торган мәктәпләрдә белем алучы һәм татар телен белә торган укучылар; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче рус телле укучылар өчен)*;

б) төп гомуми белем бирү баскычы өчен (5-9 сыйныфлар) татар теле һәм татар әдәбиятыннан (*укыту татар телендә алып барыла торган мәктәпләр һәм сыйныфлар; укыту рус телендә алып барыла торган мәктәпләрдә белем алучы һәм татар телен белә торган укучылар; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче рус телле укучылар өчен)*;

в) гомуми урта (тулы) белем бирү баскычы өчен (10-11 сыйныфлар) татар теле һәм татар әдәбиятыннан (*укыту татар телендә алып барыла торган мәктәпләр һәм сыйныфлар; укыту рус телендә алып барыла торган мәктәпләрдә белем алучы һәм татар телен белә торган укучылар; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче рус телле укучылар өчен)*;

г) төп гомуми белем бирү баскычы( 5-9 сыйныфлар) һәм гомуми урта (тулы) белем бирү баскычы өчен (10-11 сыйныфлар) татар халкы һәм Татарстан тарихыннан.

3. Бу боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Министрның беренче урынбасары Д.М.Мостафин

Зиннәтуллин Р.К.
292-59-93